**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«01 » июль 2021 ел Мәләкәс авылы №12

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 16 декабрендәге «Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 20 номерлы карары үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 16 декабрендәге «Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 20 номерлы карары (2021 елның 30 мартындагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Ю.П.Васильев